МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.01.2024 Казан ш № 24

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 4 маендагы 285 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 4

маендагы 285 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 3 ноябрендәге 817 номерлы, 2023 елның 12 апрелендәге 284 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертеп, 2.3.4 пунктның ундүртенче абзацын түбәндәгечә бәян итәргә:

«Пенсиягә өстәмә түләүләрне (тиешле елларны эшләгән өчен пенсияләрне) билгеләү һәм түләү турында мәгълүмат Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформасында урнаштырыла.

Министр Э.Ә. Зарипова